ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 23 ноябреннән № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең
Енабердино авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы студентларыннан, вакытлы хәрби хезмәттәгеләрдән һәм контракт буенча хезмәт итүчеләрдән тыш, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә.

2. Алынган үзара салым акчаларын Енабердино авылында мәктәптән алып Ленин урамына кадәр җәяүлеләр тротуарын төзекләндерү буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.

3. Енабердино авылы, Клуб урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Н.Никифоров